Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Баграж-Никольский авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

08 ноября 2019 ел N 2

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлегенең Дальняя Ивановка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлегенең Дальняя Ивановка авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын 2019 елның 22 ноябрендә, 09 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Баграж-Никольский авыл җирлегенең Дальняя Ивановка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, сметалар төзү һәм техник күзәтү өчен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыенын Дальняя Ивановка авыл мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Дальняя Ивановка авылы, Яшьләр урамы, 27 нче йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Дальняя Ивановка авылы, Яшьләр урамы, 26 нчы йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Баграж-Никольский
авыл җирлеге башлыгы
вазифаларын башкаручы А.В. Исаев